**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Кече Чынлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кече Чынлы авылында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**2021 нче елның 08 нче декабре Кече Чынлы авылы №1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы “Кече Чынлы авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Кече Чынлы авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советы 07.10.2019 ел, № 48/1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда, гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, 2021 нче елның 08 нче декабрендә төзелгән хисап комиссиясенең, 2021 елның 08 нче декабрендә узган халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 1049 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны 638, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның 60,82 % ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 636 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның 99,69% ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучылардан 2 кеше тавыш бирде, бу 0,31% ын тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә КАРАР ИТЕЛДЕ:

1. 2021 нче елның 08 нче декабрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Кече Чынлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кече Чынлы авылында 2021 нче елның 08 нче декабрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Кече Чынлы авылының Казан һәм Чапаев урамнарының гамәлдәге юлларына вак таш салу;
- Кече Чынлы авылының Гагарин һәм Мир урамнары юл челтәрен ремонтлау” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2022 нче елда Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Кече Чынлы авылының Казан һәм Чапаев урамнарының гамәлдәге юлларына вак таш салу;

- Кече Чынлы авылының Гагарин һәм Мир урамнары юл челтәрен ремонтлау.

4. Әлеге карарны, Крупская урамының 2 нче йортында урнашкан Кече Чынлы авыл җирлегенең административ бинасының, Крупская урамының 4 нче йортында урнашкан Кече Чынлы мәктәп бинасының махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче: Г.Ш.Халитов